____ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ

**ТЕНЕШ**

**ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЁЛОГЫ**

**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ**

**ПОСЁЛОК СОВЕТЫ**

# КАРАРЫ

Тенеш ш.т.п. № 129-рс

**Поселок Советы тарафыннан кабул ителгән - 2020 елның 15 июнендә**
**Тенеш ш.т.п. башлыгы тарафыннан 2020 елның 15 июнендә имзаланган**

**Дүртенче чакырылыш «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советы депутатларын сайлауларны билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы, 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 105 статьясындагы 1 өлеше, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге уставының 16 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советы **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. 2020 елның 13 сентябренә «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советы депутатларын сайлауларны билгеләргә.
2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә: Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Тенеш ш.т.п., Ленин ур., 8 йорт; Татарстан Республикасы, Кама Тамагы

муниципаль районы, Тенеш ш.т.б., Пионер ур., 18 йорт, шулай ук Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. “Идел таңнары” газетасында әлеге карарны кабул ителгән көннән алып биш көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге башлыгы, «Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советы рәисе

И. Т. Гыйниятов